0+

Флёра Тарханова

# Карлыган белән чия



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Т21

Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен

Рәссамы *Влада Семёнова*

**Тарханова, Ф. Г.**

Т21 Карлыган белән чия : балалар өчен шигырьләр һәм табышмаклар / Флёра Тарханова ; [рәссамы Влада Семёнова]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. — 95 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-03261-2

Китапка Флёра Тарханованың балаларга аңлаешлы җиңел, матур тел белән язылган иң яхшы шигырьләре һәм табышмаклары тупланды. Укучылар шигырь геройлары белән бергә кызыклы хәлләргә очрый, тирә-юньне, дөньяны танып белергә өйрәнә. Шигъри формада язылган табышмаклар балаларның уйлау, фикерләү сәләтен үстерә.
Китап мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03261-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Тарханова Ф. Г., 2016

# УҢГАН КЫЗ



# Ялт иттерде бүлмәне

Ләгәнгә җылы су салып,
Чүпрәк алып кулына,
Диана өй җыештыра —
Ярдәмләшеп тор гына.

Башта дымлы чүпрәк белән
Сөртеп чыкты тузанны,
Аннары келәм чистартты,
Кәнәфи дә кузгалды.

Өстәл астына да керде,
Җитез генә үрмәләп,
Ә идәнне иң соңыннан
Юып чыктык бергәләп.

Тырышып эшли Диана,
Әнисеннән күрмәле:
Коймак өлгергән арада
Ялт иттерде бүлмәне.





## Үзем сибәрмен суны

Дәү әни, күрче, гөлләрең
Башын игән, корышкан,
Шәлперәйгән яфраклары,
Чәчкәләре бөрешкән.

Тизрәк чиләгемне алып,
Су тутырыйм краннан,
Җылынгач та, гөл төбенә
Сибеп чыгармын аннан.

Зур, биек булып үссеннәр,
Матур чәчкә атсыннар,
Өебезгә көннәр буе
Хуш исләр таратсыннар.

Эчертмәсәң, үләләр бит,
Белмисеңмени шуны?
Моннан соң бу гөлләреңә
Үзем сибәрмен суны.



## Уңган кыз



Нәни булсам да, әнине
Зур эшләрдән коткарам:
Җиң сызганып керләр юам —
Юган саен остарам.

Ашагач та юып куям
Чынаякны, кашыкны;
Чистармыйча калмасын дип,
Эшләгәндә ашыкмыйм.

Ашыгырга һич ярамый:
Кулымнан төшеп китсә,
Тәлинкә-чынаякларның
Барысы ватылып бетсә,

Ни диярмен әниемә —
Ул бит мине орышыр,
Булдыра алмыйсың, диеп,
Эшләтмәскә тырышыр.

Ә минем килә эшлисем,
Зурларга булышасым.
Булышырга бик яратам —
Эшем генә ошасын.

## Килде пилмән ашыйсы

Әй беркөнне шундый итеп
Килде пилмән ашыйсы,
Тик белмимен — бу пилмәнне
Ничек итеп ясыйсы?

Әнием өйдә чагында
Ник торам соң аптырап? —
Камырын да басып бирде,
Итен дә куйды турап.

Пилмәннәрне мин дә бөктем,
Кырыйларын бөрмәләп...
Бигрәк тәмле була икән,
Пешергәчтен бергәләп.





## Без бәлеш пешерәбез

Бүген бәйрәм көне итеп,
Бәлеш пешерик әле,
Торт алмыйча калганбыз, дип,
Күңел төшермик әле.

Уклауны, куна тактасын
Җайлап куйыйк өстәлгә,
Тәмләткечләрне чыгарыйк,
Кирәксә, дип, өстәргә.

Йомырка, онны алыйк та
Каймакка туглап салыйк,
Тоз-шикәрне дә онытмыйк –
Тәмләп пешереп карыйк.

Камыр ясыйбыз бергәләп,
Аннан бәлеш бөгәбез;
Борынга буялган оннан
Рәхәтләнеп көләбез.

Матур булып пешеп чыкты –
Мичтән алдык бәлешне,
Тәмләп үзебез ашадык
Иң беренче өлешне.

# Эчтәлек

## Уңган кыз


Ялт иттерде бүлмәне . . . . . 4
Үзем сибәрмен суны . . . . . 5
Уңган кыз . . . . . 6
Килде пилмән ашыйсы . . . . . 7
Без бәлеш пешерәбез . . . . . 8
Конфетыңны качырма . . . . . 9
Яшьтән өйрән тәртипкә! . . . . . 10
Сыйныфташлар . . . . . 11
Нәни Әдилә . . . . . 12
Индира китап укый . . . . . 13
Әйдә, эчер чәеңне! . . . . . 14
Җәйге кояш . . . . . 15
Син, дәү әни, шундый ягымлы . . . . . 16
Ничек өлгерә икән? . . . . . 17
Нәфисә . . . . . 18
«Өйләнсәм», ни диярсең? . . . . . 19
Гөлнара мәктәпкә бара . . . . . 20
Укыр «яхшы» билгегә . . . . . 21
Кораб . . . . . 22
Әнием . . . . . 23
Әйдә, ал! . . . . . 24
Нурлан . . . . . 26
Яңгыр күле . . . . . 28
Гөберле бака . . . . . 30
Монда нинди хата бар? — Кем аны эзләп табар? . . . . . 32
    Диананы эзлибез . . . . . 32
    Кайнар аш . . . . . 34
    Яулык . . . . . 35
    Бизәм хочу, дәү әни! . . . . . 36
Бриллиант төймә бармы соң? . . . . . 37


## Табигать кочагында


Табигать кочагында . . . . . 40
Җәйнең матур бер чагы . . . . . 42
Такыялар үрәбез . . . . . 42

Карлыган белән чия . . . . . 43
Чәчкәләр чәчтем түтәлгә . . . . . 44
Торалар гаскәр кеби . . . . . 45
Быел эссе котыра . . . . . 46
Суган белән Сарымсак . . . . . 47
Батыр Күгәрчен . . . . . 49
Пенсиягә китәр вакыт... . . . . . 50
Малайлар гәп коралар . . . . . 54
Уйнаклашып, кар ява . . . . . 57
Күзләр менде маңгайга . . . . . 57
Шомырт . . . . . 58
Сиреньнәр чәчәк аткан . . . . . 59
Әдәпсез Марат . . . . . 60
Катлы кәбестә . . . . . 62
Әйдәгез Яңа елга! . . . . . 63
Шапшак малай . . . . . 64
Чебиләр . . . . . 66
Мин һаман үсәм әле . . . . . 68
Уйнавы рәхәт тышта . . . . . 69
Суык патшалык итә . . . . . 69
Менә сиңа могҗиза! . . . . . 70
Урман кызы — гүзәл чыршы турында әкият . . . . . 72
Кәләпүшне кыңгыр салып . . . . . 74
Җырларга өйрәнәбез . . . . . 76

**Нигә ул шулай икән?**

Нәни шигырьләр . . . . . 78
Уйлап тап! *(Табышмаклар)* . . . . . 84
Нигә ул шулай икән? . . . . . 90

Литературно-художественное издание

Для детей дошкольного и школьного возраста

**Тарханова** Флёра Габдрахмановна

СМОРОДИНА И ВИШНЯ

Казань. Татарское книжное издательство. 2016

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен

**Тарханова** Флёра Габдрахман кызы

КАРЛЫГАН БЕЛӘН ЧИЯ

Мөхәррирләре *Э. Т. Кәлимуллина, Р. Г. Сәлахов*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. Н. Мусина*
Корректорлары *И. И. Галиева, Г. Г. Зиннәтуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.09.2016. Форматы 84×100 1/16.
Шартлы басма табагы 9,36. Тиражы 2000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

**Маркетинг бүлеге:**
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет:**
**http://www.tatkniga.ru**

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.